РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ          Биккол ав.          КАРАР

«11» ноябрь  2021 ел                                        № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Биккол авылында граждannар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»  2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында  Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Тукай, М.Җәлил, Вахитов урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә
2. 2021 елның 26 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында  Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә
3. 2021 елның 27 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында  Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Заречная, Ленин, Полевая урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә
4. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарыла.
5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2022 елда Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000

сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү техникасын урнаштыру өчен торак булмаган бинаны реконструкцияләү;
- Биккол авылында юллар салу өчен вак таш сатып алу;
- Биккол авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы карап тоту »

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Әхмәтшина